**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О внесении изменений в Указ Президента Республики Татарстан «О Правительственной комиссии Республики Татарстан по профилактике правонарушений»

В связи с изменениями в федеральном законодательстве в сфере профилактики правонарушений **постановляю:**

1. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 9 января 2010 года № УП-1 «О Правительственной комиссии Республики Татарстан по профилактике правонарушений» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 16 сентября 2010 года № УП-616, от 31 декабря 2010 года № УП-897, от 25 июля 2011 года № УП-432, от 10 марта 2012 года № УП-187, от 11 июня 2012 года № УП-458, от 6 августа 2013 года № УП-716, от 4 ноября 2013 года № УП-1073, от 11 декабря 2013 года № УП-1211, от 20 февраля 2014 года № УП-183, от 8 апреля 2015 года № УП-378, от 31 марта 2016 года № УП-323, от 11 июня 2016 года № УП-527, от 5 октября 2016 года № УП-904, от 3 декабря 2016 года № УП-1062, от 14 января 2017 года № УП-7, от 9 февраля 2017 года № УП-112 и от 5 апреля 2017 года № УП-288) следующие изменения:

а) дополнить пунктом 5 следующего содержания:

«5. Рекомендовать главам муниципальных районов и городских округов Республики Татарстан обеспечить разработку и принятие мер в пределах своей компетенции по профилактике правонарушений, предусмотренных федеральным законодательством и законодательством Республики Татарстан.»;

б) пункт 5 считать пунктом 6;

в) Положение о Правительственной комиссии Республики Татарстан по профилактике правонарушений изложить в новой редакции согласно приложению.

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** — **Р.Н. Минниханов**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань,Кремль
06 мая 2017 года
№ УП-366

Приложение
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «06» мая 2017 года

№ УП-366

**Положение**
**о Правительственной комиссии Республики Татарстан**
**по профилактике правонарушений**

I. Общие положения

1. Правительственная комиссия Республики Татарстан по профилактике правонарушений (далее – Комиссия) является постоянно действующим республиканским координационным органом в сфере профилактики правонарушений, образованным для обеспечения согласованных действий субъектов профилактики правонарушений и их должностных лиц, а также лиц, участвующих в профилактике правонарушений, при реализации мер профилактики правонарушений на территории Республики Татарстан.

2. Комиссия в своей деятельности руководствуется Конституцией Российской Федерации, федеральными конституционными законами, федеральными законами, указами и распоряжениями Президента Российской Федерации, постановлениями и распоряжениями Правительства Российской Федерации, иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, Конституцией Республики Татарстан, законами Республики Татарстан, указами и распоряжениями Президента Республики Татарстан, иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан, а также настоящим Положением.

II. Основные задачи Комиссии

3. Основными задачами Комиссии являются:

а) координация деятельности органов исполнительной власти Республики Татарстан, а также взаимодействие с территориальными органами федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан, органами местного самоуправления и лицами, участвующими в профилактике правонарушений, по исполнению федерального законодательства и законодательства Республики Татарстан в сфере профилактики правонарушений, включая вопросы профилактики

злоупотребления алкогольной продукцией, пивом, табаком и формирования здорового образа жизни среди населения в Республике Татарстан;

б) обеспечение исполнения решений Правительственной комиссии по профилактике правонарушений, образованной Правительством Российской Федерации;

в) подготовка предложений Президенту Республики Татарстан о реализации государственной политики в сфере профилактики правонарушений на территории Республики Татарстан;

г) выработка предложений по вопросам профилактики правонарушений, направленных на активизацию борьбы с алкоголизмом, наркоманией, незаконной миграцией, ресоциализацию лиц, отбывших уголовное наказание в виде лишения свободы и (или) подвергшихся иным мерам уголовно-правового характера, и других мер по снижению уровня правонарушений на территории Республики Татарстан;

д) выработка комплексных мер по основным направлениям профилактики правонарушений, их внедрение в практическую деятельность субъектов профилактики правонарушений и их должностных лиц, а также лиц, участвующих в профилактике правонарушений, при реализации мер профилактики правонарушений на территории Республики Татарстан;

е) организация и проведение общереспубликанских профилактических мероприятий, а также профилактических мероприятий на территориях двух и более муниципальных районов, городских округов, направленных на снижение уровня правонарушений на территории Республики Татарстан;

ж) информирование Президента Республики Татарстан и Кабинета Министров Республики Татарстан о ходе и результатах деятельности Комиссии и принимаемых мерах по устранению причин и условий совершения правонарушений;

з) информирование общественности о работе, проводимой субъектами профилактики правонарушений и лицами, участвующими в профилактике правонарушений.

## III. Основные функции Комиссии

4. Комиссия для выполнения возложенных на нее задач осуществляет следующие основные функции:

а) принимает участие в разработке и проведении экспертизы проектов правовых актов, связанных с решением вопросов, входящих в компетенцию Комиссии;

б) принимает участие в разработке государственных программ Республики Татарстан в сфере профилактики правонарушений, а также участвует в осуществлении контроля за их реализацией, в том числе путем мониторинга эффективности реализации мер по профилактике правонарушений, предусмотренных этими программами;

в) осуществляет подготовку информационно-аналитических, справочных материалов, сведений о работе субъектов профилактики

правонарушений и их должностных лиц, а также лиц, участвующих в профилактике правонарушений, и мониторинг в сфере профилактики правонарушений;

г) информирует в установленном порядке руководителей территориальных органов федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан, органов прокуратуры в Республике Татарстан, следственных органов Следственного комитета Российской Федерации в Республике Татарстан, органов государственной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления в Республике Татарстан, осуществляющих деятельность в сфере профилактики правонарушений, а также лиц, участвующих в профилактике правонарушений, о выявленных недостатках;

д) обобщает и распространяет положительный опыт работы субъектов профилактики правонарушений и их должностных лиц, а также лиц, участвующих в профилактике правонарушений, при реализации мер профилактики правонарушений на территории Республики Татарстан;

е) осуществляет взаимодействие с общественными объединениями и иными организациями при решении вопросов профилактики правонарушений;

ж) осуществляет взаимодействие со средствами массовой информации по вопросам, отнесенным к ее компетенции;

з) проводит сбор и анализ информации о состоянии и тенденциях проявлений правонарушений, эффективности превентивной работы по вопросам, отнесенным к ее компетенции;

и) осуществляет контроль за выполнением решений Комиссии.

## IV. Основные права Комиссии

5. Комиссия имеет право:

а) подготавливать предложения по совершенствованию законодательства Российской Федерации и законодательства Республики Татарстан в сфере профилактики правонарушений;

б) запрашивать в установленном порядке у государственных органов и органов местного самоуправления, а также общественных объединений и иных организаций информацию по вопросам, отнесенным к ее компетенции;

в) приглашать на свои заседания должностных лиц государственных органов, органов местного самоуправления, а также лиц, участвующих в профилактике правонарушений;

г) формировать рабочие группы из числа представителей и специалистов заинтересованных органов и учреждений с целью изучения в муниципальных образованиях Республики Татарстан принимаемых мер профилактики правонарушений, а также основ координации деятельности и мониторинга в сфере профилактики правонарушений;

д) привлекать в установленном порядке должностных лиц и специалистов органов исполнительной власти и органов местного самоуправления, а также лиц, участвующих в профилактике правонарушений, для оказания практической помощи органам исполнительной власти в реализации мер профилактики правонарушений, выработке предложений и рекомендаций по дальнейшему совершенствованию этой работы.

## V. Порядок формирования и деятельности Комиссии

6. Положение о Комиссии и ее персональный состав утверждаются Президентом Республики Татарстан.

7. Комиссия образуется в составе председателя, заместителей председателя, ответственного секретаря и членов Комиссии.

8. В состав Комиссии могут входить представители органов государственной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти, а также руководители общественных объединений. В состав Комиссии при необходимости могут включаться иные лица. Передача полномочий члена Комиссии другому лицу не допускается.

В заседаниях Комиссии по решению председателя принимают участие представители министерств и ведомств, других органов и организаций при рассмотрении вопросов, относящихся к их компетенции. При необходимости к участию в заседаниях Комиссии могут привлекаться иные заинтересованные лица и представители средств массовой информации. Участие в работе Комиссии осуществляется на общественных началах.

9. Продолжительность заседания Комиссии не ограничена.

10. Организация деятельности Комиссии осуществляется в соответствии с планом работы Комиссии. План составляется на текущий год на основании предложений, поступивших от членов Комиссии, рассматривается на заседании Комиссии и утверждается ее председателем. В течение десяти рабочих дней после утверждения план работы Комиссии направляется членам Комиссии и иным заинтересованным лицам, а также размещается на официальном сайте Комиссии в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».

11. Заседания Комиссии проводятся под руководством ее председателя либо по его поручению под руководством заместителя председателя Комиссии и считаются правомочными, если на них присутствует более половины ее состава.

12. Заседания Комиссии проводятся, как правило, один раз в квартал. В случае необходимости по инициативе председателя Комиссии, заместителя председателя Комиссии, а также члена Комиссии по согласованию с председателем Комиссии и по представлению ответственного секретаря Комиссии могут проводиться внеочередные заседания Комиссии.

13. Председатель Комиссии:

а) осуществляет общее руководство деятельностью Комиссии;

б) утверждает план работы Комиссии;

в) утверждает повестку дня очередного заседания Комиссии;

г) дает поручения в рамках своих полномочий членам Комиссии;

д) представляет Комиссию в отношениях с федеральными государственными органами, государственными органами Республики Татарстан, органами местного самоуправления, организациями и гражданами по вопросам, относящимся к компетенции Комиссии.

14. Ответственный секретарь Комиссии:

а) обеспечивает подготовку проекта плана работы Комиссии, формирует повестку дня ее заседания, координирует работу по подготовке необходимых материалов к заседанию Комиссии, проектов соответствующих решений;

б) информирует членов Комиссии, приглашенных на заседание лиц, экспертов, иных лиц о месте, времени проведения и повестке дня заседания Комиссии, обеспечивает их необходимыми материалами;

в) оформляет протоколы заседаний Комиссии;

г) организует выполнение поручений председателя Комиссии, данных по результатам заседаний Комиссии.

## VI. Порядок принятия решения Комиссии

15. Решения Комиссии принимаются простым большинством голосов присутствующих на заседании членов Комиссии с учетом представленных в письменной форме мнений членов Комиссии, отсутствующих на заседании. При равенстве голосов решающим является голос председательствующего на заседании Комиссии.

Члены Комиссии, не согласные с принятым решением в целом или его отдельными положениями, имеют право в письменном виде изложить свое особое мнение, которое подлежит обязательному приобщению к протоколу заседания Комиссии. Особое мнение должно быть представлено членами Комиссии ответственному секретарю Комиссии в течение одного рабочего дня со дня окончания заседания Комиссии.

16. Решение Комиссии оформляется протоколом заседания Комиссии, который подписывается председательствующим на заседании. Протоколы заседаний Комиссии оформляются в течение пяти рабочих дней со дня окончания заседания.

17. Решения, принимаемые Комиссией в соответствии с ее компетенцией, являются обязательными для исполнения руководителями исполнительных органов государственной власти Республики Татарстан.

18. Для реализации решений Комиссии могут издаваться указы и распоряжения Президента Республики Татарстан, постановления и распоряжения Кабинета Министров Республики Татарстан, а также даваться поручения Президента Республики Татарстан и Премьер-министра Республики Татарстан.

19. В случае необходимости ответственный секретарь Комиссии подготавливает и заверяет выписки из протокола заседания Комиссии по отдельным вопросам.

20. Протокол публикуется на официальном сайте Комиссии в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» в течение десяти рабочих дней со дня его подписания председательствующим на заседании Комиссии.

По поручению председателя Комиссии информация о решениях Комиссии может передаваться средствам массовой информации для опубликования, а также размещаться на официальных сайтах территориальных органов федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан, органов государственной власти Республики Татарстан и органов местного самоуправления в Республике Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».

## VII. Обеспечение деятельности Комиссии

21. Материально-техническое и организационное обеспечение деятельности Комиссии осуществляется Аппаратом Кабинета Министров Республики Татарстан.

22. Комиссия имеет бланк со своим наименованием.

___________

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Президентының «Хокук бозуларны профилактикалау буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәт комиссиясе турында» Указына үзгәрешләр кертү турында

Хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә федераль законнарга үзгәрешләр кертелү белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Хокук бозуларны профилактикалау буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәт комиссиясе турында» 2010 елның 9 гыйнварындагы ПУ-1 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 16 сентябрендәге ПУ-616 номерлы, 2010 елның 31 декабрендәге ПУ-897 номерлы, 2011 елның 25 июлендәге ПУ-432 номерлы, 2012 елның 10 мартындагы ПУ-187 номерлы, 2012 елның 11 июнендәге ПУ-458 номерлы, 2013 елның 6 августындагы ПУ-716 номерлы, 2013 елның 4 ноябрендәге ПУ-1073 номерлы, 2013 елның 11 декабрендәге ПУ-1211 номерлы, 2014 елның 20 февралендәге ПУ-183 номерлы, 2015 елның 8 апрелендәге ПУ-378 номерлы, 2016 елның 31 мартындагы ПУ-323 номерлы, 2016 елның 11 июнендәге ПУ-527 номерлы, 2016 елның 5 октябрендәге ПУ-904 номерлы, 2016 елның 3 декабрендәге ПУ-1062 номерлы, 2017 елның 14 гыйнварындагы ПУ-7 номерлы, 2017 елның 9 февралендәге ПУ-112 номерлы һәм 2017 елның 5 апрелендәге ПУ-288 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) түбәндәге эчтәлекле 5 пунктны өстәргә:

«5. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына хокук бозуларны профилактикалау буенча федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган чараларны эшләүне һәм кабул итүне үз вәкаләтләре чикләрендә тәэмин итүне тәкъдим итәргә.»;

б) 5 пунктны 6 пункт дип санарга;

в) Хокук бозуларны профилактикалау буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәт комиссиясе турындагы нигезләмәне кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2017 ел, 06 май
№ ПУ-366

Татарстан Республикасы
Президентының
2017 елның « 06 » маендагы
ПУ- 366 номерлы Указына
кушымта

**Хокук бозуларны профилактикалау буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәт комиссиясе турында**
**нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Хокук бозуларны профилактикалау буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәт комиссиясе (алга таба – Комиссия) хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә хокук бозуларны профилактикалау субъектлары һәм аларның вазыйфаи затлары, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә хокук бозуларны профилактикалау чараларын гамәлгә ашырганда хокук бозуларны профилактикалауда катнашучы затларның үзара килештерелгән гамәлләрен тәэмин итү өчен оештырылган даими гамәлдә булган республика координацияләү органы булып тора.

2. Үз эшчәнлегендә Комиссия Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты указларына һәм боерыкларына, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары һәм боерыкларына, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Президенты указларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

## II. Комиссиянең төп бурычлары

3. Комиссиянең төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

а) Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары эшчәнлеген координацияләү, шулай ук федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, җирле үзидарә органнары һәм хокук бозуларны профилактикалауда катнашучы затлар белән хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә федераль законнарны һәм Татарстан Республикасы законнарын үтәү буенча, Татарстан Республикасында яшәүчеләрнең алкогольле продукцияне, сыра, тәмәкене чамасыз куллануын профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләрен дә кертеп, хезмәттәшлек итү;

б) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан оештырылган Хокук бозуларны профилактикалау буенча Хөкүмәт комиссиясе карарларын үтәүне тәэмин итү;

в) Татарстан Республикасы территориясендә хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында Татарстан Республикасы Президентына тәкъдимнәр әзерләү;

г) эчкечелек, наркомания, законсыз миграциягә каршы көрәшне активлаштыруга, иректән мәхрүм ителү рәвешендә җинаять җаваплылыгына һәм (яисә) җинаять-хокукый характердагы башка чараларга тартылган затларны ресоциализацияләүгә һәм Татарстан Республикасы территориясендә җинаятьчелек күләмен киметү буенча хокук бозуларны профилактикалау мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр эшләү;

д) хокук бозуларны профилактикалауның төп юнәлешләре буенча комплекслы чаралар эшләү, аларны хокук бозуларны профилактикалау субъектлары һәм аларның вазыйфаи затлары, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә хокук бозуларны профилактикалау чараларын гамәлгә ашырганда хокук бозуларны профилактикалауда катнашучы затларның гамәли эшчәнлегендә куллануга кертү;

е) Татарстан Республикасы территориясендә җинаятьчелек дәрәҗәсен киметүгә юнәлдерелгән гомумреспублика профилактика чараларын, шулай ук ике яисә аннан күбрәк муниципаль районнар, шәһәр округлары территорияләрендә профилактика чараларын оештыру һәм үткәрү;

ж) Комиссия эшчәнлеге барышы һәм нәтиҗәләре, җинаятьләр һәм башка хокук бозулар кылуның сәбәпләрен һәм шартларын бетерү буенча күрелгән чаралар турында Татарстан Республикасы Президентына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына хәбәр итү;

з) хокук бозуларны профилактикалау субъектлары һәм аларның вазыйфаи затлары, шулай ук хокук бозуларны профилактикалауда катнашучы затларның башкарган эшләре турында җәмәгатьчелеккә хәбәр итү.

## III. Комиссиянең төп функцияләре

4. Комиссия үзенә йөкләнгән бурычларны гамәлгә ашыру өчен түбәндәге төп функцияләрне башкара:

а) Комиссия компетенциясенә кергән мәсьәләләрне хәл итү белән бәйле хокукый акт проектларын эшләүдә һәм аларга экспертиза үткәрүдә катнаша;

б) хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшләүдә катнаша, шулай ук аларның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыруда, шул исәптән әлеге программаларда каралган хокук бозуларны профилактикалау чараларын гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген мониторинглау юлы белән дә, катнаша;

в) хокук бозуларны профилактикалау субъектлары һәм аларның вазыйфаи затлары, шулай ук хокук бозуларны профилактикалауда һәм хокук

бозуларны профилактикалау өлкәсендә мониторинг уздыруда катнашучы затларның эшчәнлеге турында мәгълүмати-аналитик, белешмә материаллар, мәгълүматлар әзерләүне гамәлгә ашыра;

г) хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә эшчәнлек алып баручы федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасында прокуратура органнары, Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасындагы тикшерү органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә, шулай ук хокук бозуларны профилактикалауда катнашучы затларга ачыкланган җитешсезлекләр турында билгеләнгән тәртиптә хәбәр итә;

д) хокук бозуларны профилактикалау субъектларының һәм аларның вазыйфаи затларының, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә хокук бозуларны профилактикалау чараларын гамәлгә ашырганда хокук бозуларны профилактикалауда катнашучы затларның уңай эш тәҗрибәсен гомумиләштерә һәм тарата;

е) хокук бозуларны профилактикалау мәсьәләләрен хәл иткәндә иҗтимагый берләшмәләр һәм башка оешмалар белән үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра;

ж) үз компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра;

з) җинаятьчел чагылышларның торышы һәм тенденцияләре, үз компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча алдан кисәтү эшенең нәтиҗәлелеге турындагы мәгълүматны җыя һәм анализлый;

и) Комиссия карарларының үтәлешен тикшереп тора.

## IV. Комиссиянең төп хокуклары

5. Комиссия түбәндәге хокукларга ия:

а) хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын һәм Татарстан Республикасы законнарын камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләргә;

б) дәүләт органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук җәмәгать берләшмәләреннән һәм башка оешмалардан үз компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча билгеләнгән тәртиптә мәгълүмат соратып алырга;

в) үз утырышларына дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары вазыйфаи затларын, шулай ук хокук бозуларны профилактикалауда катнашучы затларны чакырырга;

г) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә гамәлгә ашырылучы хокук бозуларны профилактикалау чараларын, шулай ук хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә эшчәнлекне координацияләү һәм мониторинглау нигезләрен өйрәнү максатларында кызыксынган органнар һәм учреждениеләр вәкилләре һәм белгечләреннән эш төркемнәре формалаштырырга;

д) хокук бозуларны профилактикалау системасы чараларын гамәлгә ашырганда, әлеге эшне алга таба камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләүдә башкарма хакимият органнарына гамәли ярдәм күрсәтү өчен башкарма хакимият органнарының һәм җирле үзидарә органнарының, шулай ук оешмаларның вазыйфаи затларын һәм белгечләрен билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә.

## V. Комиссияне формалаштыру һәм эшчәнлеге тәртибе

6. Комиссия турында нигезләмә һәм аның персональ составы Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана.

7. Комиссия рәис, рәис урынбасарлары, җаваплы секретарь һәм Комиссия әгъзалары составында төзелә.

Комиссия составына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, федераль башкарма хакимияте органнарының территориаль органнары вәкилләре, шулай ук җәмәгать берләшмәләре җитәкчеләре керергә мөмкин. Комиссия составына, кирәк булган очракта, башка затлар да кертелә ала.

8. Комиссия әгъзасы вәкаләтләрен башка затка тапшыру рөхсәт ителми.

Комиссия утырышларында рәис карары буенча үз компетенцияләренә караган мәсьәләләрне карап тикшерүдә министрлыклар һәм ведомстволар, шулай ук башка органнар һәм оешмалар вәкилләре катнаша. Кирәк булганда, Комиссия утырышларында башка кызыксынган затлар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнашырга мөмкин. Комиссия эше җәмәгать башлангычларында алып барыла.

9. Комиссия утырышы узу вакыты чикләнмәгән.

10. Комиссия эшчәнлеген оештыру Комиссиянең эш планы нигезендә гамәлгә ашырыла. Эш планы агымдагы елга Комиссия әгъзаларыннан килгән тәкъдимнәр нигезендә төзелә, Комиссия утырышында тикшерелә һәм аның рәисе тарафыннан раслана. Комиссиянең эш планы расланган көннән соң 10 көн эчендә эш планы Комиссия әгъзаларына һәм башка кызыксынган затларга җибәрелә, шулай ук Комиссиянең «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

11. Комиссия утырышлары аның рәисе яисә Комиссия рәисе кушуы буенча аның урынбасарларының берсе җитәкчелегендә үткәрелә һәм аларда составының яртысыннан күбрәге катнашса, гамәлгә хокуклы дип санала.

12. Комиссия утырышлары, кагыйдә буларак, кварталга бер тапкыр уздырыла. Кирәк булганда, Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары, шулай ук Комиссия әгъзасы инициативасы буенча Комиссия рәисе белән килештерелеп һәм Комиссиянең җаваплы секретаре тәкъдиме буенча Комиссиянең чираттан тыш утырышлары уздырылырга мөмкин.

13. Комиссия рәисе:

а) Комиссия эшчәнлеге белән гомуми идарә итүне гамәлгә ашыра;

б) Комиссиянең эш планын раслый;

в) Комиссиянең чираттагы утырышының көн тәртибен раслый;

г) үз вәкаләтләре кысаларында Комиссия әгъзаларына йөкләмәләр бирә;

д) федераль дәүләт органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга һәм гражданнарга мөнәсәбәттә Комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча Комиссия вәкиле буларак чыгыш ясый.

14. Комиссиянең җаваплы секретаре:

а) Комиссиянең эш планы проектын әзерләүне тәэмин итә, аның утырышының көн тәртибен формалаштыра, Комиссия утырышына кирәкле материалларны, тиешле карарлар проектларын әзерләү буенча эшне координацияли;

б) Комиссия әгъзаларына, утырышка чакырылган затларга, экспертларга, башка затларга Комиссия утырышы узу урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында хәбәр итә, аларны кирәкле материаллар белән тәэмин итә;

в) Комиссия утырышлары беркетмәләрен рәсмиләштерә;

г) Комиссия рәисенең Комиссия утырышлары йомгаклары буенча бирелгән йөкләмәләренең үтәлешен оештыра.

## VI. Комиссия карарларын кабул итү тәртибе

15. Комиссия карарлары, утырышка килмәгән Комиссия әгъзаларының язмача тәкъдим ителгән фикерләрен исәпкә алып, утырышта катнашкан комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар саны тигез булган очракта, Комиссиядә рәислек итүченең тавышы хәлиткеч санала.

Кабул ителгән карар белән тулысынча яисә аның кайбер нигезләмәләре белән килешмәгән Комиссия әгъзалары үзенең аерым фикерен язмача белдерергә хокуклы, ул мәҗбүри рәвештә Комиссия утырышы беркетмәсенә теркәлергә тиеш. Әлеге аерым фикер Комиссия утырышы тәмамланган көннән бер эш көне дәвамында Комиссия әгъзалары тарафыннан Комиссиянең җаваплы секретарена тәкъдим ителергә тиеш.

16. Комиссия карарлары Комиссия утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, аңа утырышта рәислек итүче кул куя. Комиссия утырышы беркетмәләре утырыш тәмамланган көннән биш көн дәвамында рәсмиләштерелә.

17. Комиссиянең үз компетенциясе нигезендә кабул иткән карарлары Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары җитәкчеләренә үтәү өчен мәҗбүри булып тора.

18. Комиссия карарларын гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы Президенты указлары һәм боерыклары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары әзерләнергә, шулай ук Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Премьер-министры йөкләмәләре бирелергә мөмкин.

19. Кирәк булган очракта, Комиссиянең җаваплы секретаре аерым мәсьәләләр буенча Комиссия утырышлары беркетмәләреннән күчермәләр әзерли һәм аларны раслый.

20. Беркетмә Комиссиядә рәислек итүче тарафыннан кул куелган көннән ун эш көне дәвамында Комиссиянең «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

Комиссия рәисе кушуы буенча Комиссия карарлары турында мәгълүмат бастыру өчен массакүләм мәгълүмат чараларына тапшырылырга, шулай ук федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында урнаштырылырга мөмкин.

## VII. Комиссия эшчәнлеген тәэмин итү

21. Комиссия эшчәнлеген матди-техник яктан һәм оештыру ягыннан тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты тарафыннан тормышка ашырыла.

22. Комиссиянең үз атамасы күрсәтелгән бланкы бар.

___________